**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТҮКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
423732, Түке авылы,
Илтимер урамы, 2 йорт.
тел. факс.: (85552) 3-44-61
e-mail: tuk-akt@yandex.ru

**СОВЕТ ТЮКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
423732, с .Тюково,
ул. Илтимерова, дом 2.
тел. факс.: (85552) 3-44-61
e-mail: tuk-akt@yandex.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**12.10.2020 г.** **№ 7**

**Актаныш муниципаль районы Түке авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 31.07.2020 ел, 268-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Түке авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Актаныш муниципаль районы Түке авыл җирлеге Советының 2017 елның 7 нче сентябре №19 карары белән расланган, Актаныш муниципаль районы Түке авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 28.2 пунктындагы 4 пунктчага «(булган очракта), муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт узган чорда хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр булдыру һәм күрсәтелгән белешмәләрне мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен» сүзләрен өстәргә.

1.2. 16 бүлекнең,16.3 пунктының 4 пунктчасында «хезмәт кенәгәсе» сүзләреннән соң «һәм (яки) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмати рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында «Түке авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Актаныш муниципаль районы
Түке авыл җирлеге Советы башлыгы Р.М.Нуртдинов